РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» май 2025 ел г. Альметьевск № 1201

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2024 елның 18 июнендәге 2133 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының»Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 27 декабрендәге 1229 номерлы карары нигезендә, муниципаль биналарда капиталь ремонт өчен кертемнәрне тулы күләмдә түләү буенча йөкләмәләрне үтәү һәм Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2025 елның 14 апрелендәге 02-01-24/19 номерлы протесты максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү

күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2024 елның 18 июнендәге 2133 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 июлендәге 2227 номерлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 3682 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 24. | Торак урыннарны наемга алу (яллаучылар өчен) | сум/кв.м | 8,57 |

27 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.М. Каюмовка (килешү буенча) йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова